# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Дәүләт милкендәге һәм җирле милектәге
мал-мөлкәтнең, акчаларның һәм кыйммәтле
кәгазьләрнең саклanышы өлкәсендәге хокук
бозулар өчен административ җаваплылык
турында

Әлеге Закон мал-мөлкәтнең, акчаларның һәм кыйммәтле кәгазьләрнең саклanышы өлкәсендәге төп сәбәпләр хуҗасызлык һәм объектларның техник торышы канәгатьсезлек тудырырлык булган хокук бозуларга каршы көрәшне көчәйтүгә юнәлдерелгән.

I статья. Дәүләт милкендәге һәм җирле милектәге предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның урындагы затларының Татарстан Республикасында милек объектларын техник яктан ныгыту кагыйдәләрен бозуларын булдырмау яисә мал-мөлкәтләрне, акчаларны һәм кыйммәтле кәгазьләрне югарыда күрсәтелгән кагыйдәләргә туры килми торган биналарда саклауны тыю турындагы эчке эшләр органнары күрсәтмәләрен үтәмәгәннәре өчен,-

урындагы затларга бердән алып өч минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

Урлашырлык шартлар тудырган шундый ук гамәлләр өчен,-

урындагы затларга өчтән алып биш минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

2 статья. Әлеге Законда күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы беркетмәләр эчке эшләр органнарының урындагы вәкаләтле

затлары тарафыннан төзелә һәм унбиш көн эчендә судка җибәрелә.

3 статья. Әлеге Законда күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләр район /шәһәр/ суды судьясы тарафыннан гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта шәхсән каралалар.

4 статья. Әгәр әлеге хокук бозулар үзләренең сыйфаты ягыннан гамәлдәге законнар нигезендә җинаять җаваплылыгына китермәсә, шушы Законда күрсәтелгән хокук бозулар өчен җаваплылык үз көченә керә.

5 статья. Хезмәт вазыйфалары мал-мөлкәтнең,акчаларның һәм кыйммәтле кәгазьләрнең сакланышын тәэмин итүдән гыйбарәт булган урындагы затлар әлеге Закон нигезендә җаваплы булалар.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1993 елның 25 мае
N 1870-XII